КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 24 июль г.Казань № 592

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы мәсьәләләре» 2006 ел, 22 февраль, 68 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы структурасына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы мәсьәләләре» 2006 ел, 22 февраль, 68 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 10 июль, 348 нче; 2007 ел, 20 апрель, 136 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2013 ел, 2 февраль, 69 нчы; 2013 ел, 24 июнь, 436 нчы; 2014 ел, 17 гыйнвар, 21 нче; 2016 ел, 20 февраль, 103 нче; 2016 ел, 6 август, 536 нчы; 2017 ел, 15 июль, 497 нче; 2017 ел, 28 ноябрь, 920 нче; 2017 ел, 28 декабрь, 1070 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1126 нчы; 2017 ел, 12 май, 350 нче; 2018 ел, 18 май, 375 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы структурасына, аны бу карарга теркәлгән кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2006 ел, 22 февраль, 68 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 24 июль, 592 нче
карары редакциясендә)

## Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы структурасы

Финанс бүлеге

Министр

Министр ярдәмчесе

Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге

**Министрның беренче урынбасары**

- Хокук экспертизасы һәм норматив документлар эшләү бүлеге
- Норматив хокук актларын теркәү һәм Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы эшчәнлеген хокукый тәэмин итү бүлеге
- Түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне оештыру һәм планлаштыру бүлеге

**Министр урынбасары**

- Җәмәгать судьялары эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге
- Җәмәгать судьялары эшчәнлеген оештыру-хокукый тәэмин итү бүлеге
- Хокукый мәгълүматлаштыру һәм компьютер системалары бүлеге
- Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары аппаратлары

**Министр урынбасары**

- Җирле үзидарә һәм муниципаль регистрны алып бару өлкәсендә норматив хокукый эш бүлеге
- Җирле үзидарә органнарына хокукый консультацион-методик ярдәм күрсәтү бүлеге
- Җирле үзидарә өлкәсендә территориаль оештыру һәм тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру мәсьәләләре бүлеге
- Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе эшчәнлеген тәэмин итү бүлекчәсе

**Эшләр идарәчесе**

- Оештыру эше һәм документлар әйләнеше бүлеге